«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАРЫ

2022 елның 3 ноябре №68

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 70 номерлы карарына үзгәреш кертү турында(08.06.2018 №75, 15.11.2018 № 94, 28.05.2019 № 113, 23.09.2020 № 6 карарлары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен, Рәис урынбасарларын, аудиторларын һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын даими нигездә гамәлгә ашыручы айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы, 881 номерлы карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен, рәис урынбасарларын, аудиторларын һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын даими нигездә гамәлгә ашыручы айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 22.08.2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә,2022 елның 1 октябреннән муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасарының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфа окладларын алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 11958 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Кирельский авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Кирельский авыл җирлеге Советы рәисе Ф.Я.Зиннәтуллин